**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Ульяновка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге составына керүче Ульяновка, Девичья Поляна һәм
Сосновка торак пунктларында

**18.10. 2021 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге составына керүче Ульяновка, Девичья Поляна һәм Сосновка авылларының торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш.
2. Алынган чараларны җибәрергә:
   - Девичья Поляна, Нагорный, Саминовка, Сосновка һәм Ульяновка торак пунктларында урам утларын монтажлауга, урнаштыруга, ремонтлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, урам утларын куллану чыгымнарын түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
   - Девичья Поляна, Нагорный, Саминовка, Сосоновка һәм Ульяновка торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;
   - Проект- смета документациясен әзерләү, топографияне, авыл территорияләрен төзекләндерү буенча экспертиза үткәрүгә чыгымнар (Ульяновка авылы тротуарына);
   - Бульдозер көрәге сатып алуга;
   - Ульяновка авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: вак таш сатып алу, фракция 20-30 мм.
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең рәсми сайтында

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Федулова И.В.